СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

**« 27» февраль 2026 ел** **№ 11**

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында" 79 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында (2021 елның 13 сентябрендәге 31 номерлы, 2022 елның 21 ноябрендәге 63 номерлы, 2023 елның 20 июлендәге 79 номерлы үзгәрешләр белән)**

2023 елның 23 декабрендәге "Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында" 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 2026 елның 19 гыйнварында "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында" 65/о номерлы боерыгы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында" 79 номерлы карары;

- Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге 79 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 13 сентябрендәге 31 номерлы карары;

- Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге 79 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында"2022 елның 21 ноябрендәге 63 номерлы карары (2021 елның 13 сентябрендәге 31 номерлы үзгәрешләр белән);

- Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге 79 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” 2023 елның 20 июлендәге 79 номерлы карары (2021 елның 13 сентябрендәге 31 номерлы, 2022 елның 21 ноябрендәге 67 номерлы).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ